АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11.09.2023 № 196

п.г.т. Алексеевское

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Уставына ярашлы рәвештә, 2023 елның 8 сентябрендәге җәмәгать тыңлаулары беркетмәсен һәм 2023 елның 8 сентябрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләре проекты буенча җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре турындагы йомгаклауны исәпкә алып

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып Кагыйдәләрен расларга (Кушымта).
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә (http://fgistp.economy.gov.ru/).
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге Советына Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен раслау турында элек кабул ителгән карарының үз көчен югалткан дип танырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында хокукый акт текстын урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы Советының экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, ТКХ һәм транспорт буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Козин Н.М.).

6. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

**Муниципаль район Башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**